**Татарстан Республикасы Азнакай район**
**Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №216-24 2023 елның «18» апреленнән

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2020 елның 16 июнендәге 357-47 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2020 елның 16 июнендәге 357-47 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның 1, 3 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru. бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин